**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 213 от 09.08.2019

**Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезендә, РФ Шәһәр төзелеше кодексы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелешкә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» 2017 елның 4 июлендәге 788 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешкә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү һәм рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны җибәрү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 ноябрендәге 261 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (4 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2.15 пунктында 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“"5) муниципаль хезмәт күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу, мәгълүмат стендларында, районның рәсми сайтында http://apastovo.tatarstan.ru/ Интернет челтәрендә;”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми сайтында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А.М.Хәсәновкә йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. Н. Гыйбадуллин**